ЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

РЕШЕНИЕ КАРАР

№ 56 2021 елның 13 сентябре

Түбән Кама муниципаль район Советының 2005 елның 29 декабрендәге 25 номерлы карары белән расланган «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242.17 статьясындагы 4 пунктның гамәлдә булуын туктатып тору турында» 2021 елның 1 июлендәге 244-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Түбән Кама муниципаль район Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Түбән Кама муниципаль район Советының 2005 елның 29 декабрендәге 25 номерлы карары белән расланган «Түбән Кама муниципаль районы» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1 14 статьяның 1 пунктындагы алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- Россия Федерациясе керемнәре чыганаклары исемлегенә һәм бюджет керемнәре чыганаклары реестрына кертү өчен үзләренә беркетелгән керемнәр чыганаклары турында белешмәләр тапшыра;»;

1.2 14 статьяның 2 пунктындагы җиденче абзацына «Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш» сүзләрен өстәргә;

1.3 15 статьяның 1 пунктындагы өченче абзацына «бюджетның бердәм счетында калдыклар белән идарә итү операцияләреннән тыш» сүзләрен өстәргә;

1.4 15 статьяның 2 пунктындагы икенче абзацына «бюджетның бердәм счетында калдыклар белән идарә итү операцияләреннән тыш» сүзләрен өстәргә;

1.5 35 статьяның 4 пунктындагы унынчы абзацында «хисап финанс елында» сүзләреннән соң «шул исәптән Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242.22 статьясы нигезендә бирелгән үтәлмәгән казначейлык тәэмин итү йөкләмәләре суммасына,» сүзләрен өстәргә;

1.6 35 статьяның 4 пунктындагы унөченче абзацында «сигезенче һәм унынчы» сүзләрен «сигезенче, унынчы һәм унберенче» сүзләренә алмаштырырга;

2. Әлеге карар, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы муниципаль берәмлеге Уставында каралган тәртиптә үз көченә кергән 1.1, 1.2 пунктларыннан тыш, 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Түбән Кама муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны социаль-икътисади үсеш, бюджет-финанс мәсьәләләре һәм муниципаль милек буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы А.Р.Метшин